


Агымдагы елнын февралендә Мордовиянен 150 кешесе мошенникларга 50 миллион сумга якын акча кvчергән. Билгесез затлар гамәлләреннән 70 тән артык кеше зыян кvргән, алар билгесез ысул белән аларнын исеменә гомуми суммасы 3,7 млн сумга якын кредит рәсмиләштергән. Тагын 29 граждан 28 млн сумнан мәхрvм калды, алар vз акчаларын декларациялиләр яки аларны куркынычсыз счетларга кvчерәләр, шул рәвешле тупланмаларны урлаудан һәм санкцияләнмәгән исәптән чыгарудан саклыйлар. Тобәкнен 19 кешесе мошенникларга бушлай белдервләр сайтында, социаль челтәрләрдә, популяр маркетплейслар платформасында товарлар сату һәм сатып алу вакытында 4,5 млн сум кvчергәннәр.

Тугыз кеше, янәсе террорчылык һәм экстремистик оешмаларны финанслау яки кешеләр зыян кvргән юл-транспорт һәлакәте очен туганнарын яки vзләрен жинаять жаваплылыгыннан коткаруларына ышанып, кvрсәтелгән реквизитлар буенча 6,5 млн сум кvчергәннәр.

Тагын 6 гариза бирvче полициягә морәжәгать иткәннәр, табыш алу һәм акчаларны инвестицияләv сылтавы белән 4,7 млн сумнан артык колак какканнарын хәбәр иткәннәр. Алты зыян кvрvче билгесезләр жибәргән ссылка буенча узган һәм 200 мен сумнан артык югалткан. Биш кеше мессенджерда vзләре белән танышлары аралашуына ышанган һәм аларга 600 мен сум бурычка кvчергәннәр.

Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы гражданнарга билгесез затлар белән аралашканда саклык кvрсәтергә кинәш итә. Беркемгә дә шәхси мәгълvматларны хәбәр итмәгез - финанс учреждениеләре хезмәткәрләре һәм полиция хезмәткәрләре беркайчан да мондый мәгълvматны телефон аша сорамый. Карта буенча операцияләр турында белдервләрне тоташтырыгыз - әгәр сез эшләмәгән сатып алу турында смс килгән икән, кичекмәстән счетны блоклагыз. Момкин булганча антивируслардан файдаланыгыз. Чит кешеләрдән сылтамалар буенча кvчмәгез. Әгәр дә ул дустыннан килгән икән, аны ачарга ашыкмагыз, ана шалтыратыгыз! Мошенникларнын анын аккаунтын ватуы ихтимал. Танышлар исеменнән акча сорасалар, мәгълvматны тикшерегез.